СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел « 24 » октябрь** **№ 280**

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм файдалануга бирү максатында Арча муниципаль районы муниципаль милке исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә, Арча район Советы КАРАР бирде:

1. Кушымта итеп бирелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм файдалануга бирү максатында Арча муниципаль районы муниципаль милке исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен (алга таба-Исемлек) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының икътисадый үсеш, авыл хуҗалыгы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

*Арча муниципаль район башлыгы,*
район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 24 октябрь
280 номерлы карары белән
расланган

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм файдалануга бирү максатында Арча муниципаль районы муниципаль милке исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибе**

## I. Төп нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә эшләнде һәм өченче затлар хокукыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), бары тик кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм файдалануга бирү максатында гына кулланыла ала торган Арча муниципаль районы казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәт (алга таба-мөлкәт) исемлеген (алга таба - Исемлек) формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару процедурасын билгели.

1.2. Исемлекне формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару буенча бурычлар Арча муниципаль районының вәкаләтле органына - Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына (алга таба - Палата) йөкләнә.

1.3. Исемлек, шулай ук аңа кертелә торган барлык үзгәрешләр Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән раслана.

## II. Исемлекне формалаштыру тәртибе

2.1. Исемлекне формалаштыру түбәндәге нигездә башкарыла:
кече һәм урта эшмәкәрлек субъектының Палатага мөрәҗәгате;
Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Палатага нигезле мөрәҗәгате;
Палата инициативасы буенча.

2.2. Исемлеккә кертеләләр:
торак булмаган аерым торучы биналар;
цоколь катларының торак булмаган биналары;
кертеп урнаштырылган торак булмаган биналар.

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 18

статьясының 4 өлешендә күрсәтелгән исемлектәге дәүләт һәм муниципаль милекне, "Дәүләт яисә муниципаль милектәге һәм арендалана торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан күчемсез мөлкәтне аерып алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мондый мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләп алу һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39_3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш, сату тыела. Мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга субарендага бирүдән һәм "Көндәшлекне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17_1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында билгеләнгән очракларда субарендага бирүдән тыш, әлеге мөлкәткә карата аннан файдалану хокукларын алыштыру, аларны хуҗалык эшчәнлегенең теләсә кайсы башка субъектларының устав капиталына салу һәм мондый мөлкәттән файдалану хокукларын тапшыру, мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча хокукларны һәм бурычларны өченче затларга (күчерү) бирү тыела.

2.3. Милекне Исемлеккә кертү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

2.3.1. «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкенең күчемсез милек объекты исемлегенә кертелгән хокукына дәүләт теркәве булуы;

2.3.2. Исемлеккә кертелә торган милеккә өченче затларның хокуклары булмау (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш);

2.3.3. тәкъдим ителгән мөлкәтнең гражданлык әйләнеше тыелган яки чикләнгән мөлкәткә каравы турында билгеләре булмау;

2.3.4. мөлкәт Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкару өчен файдаланылмый;

2.3.5. мөлкәтнең муниципаль милекне хосусыйлаштыруның гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә расланган фараз планнарына кертелмәгән булуы.

2.4. Милек Исемлектән түбәндәге очракларда төшерелергә мөмкин: Исемлек басылып чыккан көннән соң өч ай эчендә әлеге Тәртиптә күрсәтелгән максатлар өчен объектка ихтыяҗ булмаса;

2.4.1. мөлкәтне Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкару өчен файдалану зарурлыгы булса;

2.4.2. мөлкәт Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары карары нигезендә башка максатларда файдаланылса.

2.4.3.Мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру турындагы карар Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән кабул

ителә.

2.5. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендага бирү «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы нигезендә башкарыла.

## III. Исемлекне алып бару тәртибе

3.1. Исемлекне алып бару - Исемлеккә кертү, төшереп калдыру һәм мөлкәт турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү. Исемлекне алып бару Тәртипнең 2 бүлеге нигезендә башкарыла.

3.2. Исемлек Тәртипкә кушымта нигезендә электрон рәвештә һәм кәгазьдә алып барыла.

## IV. Исемлекне рәсми бастырып чыгару тәртибе

Расланган Исемлек һәм Исемлеккә кертелгән үзгәрешләр расланган көннән алып 30 календарь көн эчендә Арча муниципаль районы җирле үзидарә органының Рәсми бюллетенендә, Арча муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында мәҗбүри урнаштырылырга тиеш.

*Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм файдалануга бирү максатында Арча муниципаль районы муниципаль милке исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибенә 1 нче кушымта*

Форма

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм файдалануга бирү максатында Арча муниципаль районы муниципаль милке Исемлеге**

| N | Мөлкәт (объект) атамасы | Объектның адресы | Шәхси сыйфатламалары (мәйданы, катлылыгы, төзекләндерелеше һ. б. ) | Катлауландыруның төре, вакыты һәм нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |